| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Медведка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2019 елның 16 ноябренә 9 сәгать 00 минутка Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Медведка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарылырга тиешле сорауны расларга:

2020 елда Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Медведка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән кала, 2000 сум күләмендә үзара салым тапшыру һәм аларны түбәндә күрсәтелгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

I. Җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту:

- Медведка авылында юлларны кардан чистарту (Дорожная);
- Дорожная урамында светоидлы яктырткычлар урнаштыру.

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны Ивановка авыл җирлеге Медведка авылында урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева